**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**08.11.2019** **№ 1949**

**2020 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен муниципаль берәмлек балаларын махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча бәя нормативларын раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча Методик рекомендацияләрне раслау турында”, 2010 елның 5 июлендәге 545 номерлы карарының 3 пункты нигезендә, шулай ук мәгариф учреждениеләре укучыларын йөрткәндә автомобиль транспорты белән куллану нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгәннәрне 2020 елга расларга:

2020 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен муниципаль берәмлек балаларын махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча бәя нормативлары (1 нче кушымта);

гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен балаларны махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча бәяләрне исәпләү тәртибе турында нигезләмә (2 нче кушымта).

2. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы” МКУсенә әлеге карарның 1 пунктында расланган, гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен муниципаль берәмлек балаларын махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча бәя нормативлары нигезендә финанслауны тәэмин итүне киңәш итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары – “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге” МКУ начальнигы Н.К.Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта
«Расланган»
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты карары белән
08.11.2019 № 1949

2020 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен муниципаль берәмлек балаларын махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча бәя нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделенең атамасы | Ике ставкалы нормативның күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, бер елга сум | автотранспорт чарасының бер километр узган арага ставка, бел елга сум |
| КАВЗ | 116398 | 37,42 |
| ПАЗ | 116656 | 37,35 |
| ГАЗ «Газель» | 110767 | 30,41 |
| УАЗ | 110314 | 29,04 |
| FIAT | 110057 | 27,47 |
| Peugeot Boxer | 110572 | 27,11 |
| Ford Transit | 110829 | 30,37 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 119128 | 35,31 |

2 нче кушымта
«Расланган»
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты карары белән
08.11.2019 № 1949

# Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен балаларны махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча бәяләрне исәпләү тәртибе турында Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен балаларны махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча бәяләрне исәпләү механизмын ачыклый (алга таба – муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәтне бирү бәясе муниципаль хезмәт бирүне норматив бәясе, автотранспорт чараларының саны һәм автотранспорт чарасының хисап периодында фактта узган юлы нигезендә исәпләнелә.

1.3. Муниципаль хезмәтне бирүнең нормативлары “Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан ел саен раслаалар.

1.4. Муниципаль хезмәт бәясен формалаштырганда автотранспорт чарасының фактта узган юлы турында мәгълүмат Татарстан Республикасында аерым автотранспорт чараларының бердәм мониторингы системасы мәгълүматлары буенча, автотранспорт чарасының хисап елында расланган автотранспорт чарасының маршруты паспорты кысаларында фактта узган юлы буларак кабул ителә.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. *i*-лы муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнелә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

монда:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - $m$ модельле автотранспорт чарасының фактта узган юлы, километр;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртү өчен балаларны махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча бәя нормативлары ставкасы, бер километрга, сум;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртү өчен балаларны махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча бәя нормативлары ставкасы, бер автотранспорт чарасына, сум;

$M_m$ - $m$ модельле автотранспорт чараларының саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль бермәлектә кулланыла торган автобус моделе номеры;

$k$ - муниципаль бермәлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.